РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА КУДАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОДАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2019 № 25

**«Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл жирлеге Башкарма комитеты житәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварындагы №8 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законга туры китерү максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл жирлеге Башкарма комитеты житәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварындагы №8 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.5 пунктының 10 абзацын яна редакциядә бәян итәргә:

"планлаштыру структурасы элементы" - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару территориясе».

1.2. 5 бүлектәге 5.8 пункны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип табылганда, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган житешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, оешма яки №210 Федераль законның 16 маддәсенең 1.1 өлешендә каралган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында, алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

2. Карар текстының калган өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Житәкче** **Г.А.Хайсарова**